ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

25.10.2020 № 3

На №______________от________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлегенең Ватан авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 2020нче елның 25нче октябрендә узган «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлеге Ватан авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы? - Ватан авылы чишмәсен төзекләндерү, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмә төзелде:

Халык җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучыларның 17се, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 10 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 10 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Ватан авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Ватан авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән гражданнарның ташламалы категориясеннән тыш, һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Ватан авылында 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы? - Ватан авылы чишмәсен төзекләндерү, дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Ватан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Кәримов Ф. Р.